КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 июль г.Казань № 527

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Көнбагыш мае һәм ак шикәр җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 30 апрель, 298 нче карары белән расланган 2021 елда рафинадланган бутильләштерелгән көнбагыш мае һәм (яки) ак шикәр җитештерүгә һәм ваклап сәүдә итү оешмаларына реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен көнбагыш мае һәм (яки) ак шикәр җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслана торган субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Көнбагыш мае һәм ак шикәр җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2021 ел, 30 апрель, 298 нче карары белән расланган 2021 елда рафинадланган бутильләштерелгән көнбагыш мае һәм (яки) ак шикәр җитештерүгә һәм ваклап сәүдә итү оешмаларына реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен көнбагыш мае һәм (яки) ак шикәр җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслана торган субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацта «үз җитештерүендәге» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартларында» сүзеннән соң «, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «үз җитештерүендәге» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартларында» сүзеннән соң «, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) үлчәп төрү һәм алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ваклап сәүдә итү оешмаларына шулай ук Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы билгеләгән хуҗалык итүче субъектлар, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары раслаган хуҗалык итүче субъектлар керә, аларның әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән шартларда сатып алынган көнбагыш мае һәм (яки) ак шикәр белән әлеге хуҗалык итүче субъектларын тәэмин итү буенча гамәлдәге йөкләмәләре була;»;

5 пунктның тугызынчы абзацында «һәм бәяләү» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;»;

8 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алуда катнашучы тарафыннан 2021 елның 1 апреленнән 30 сентябренә кадәр көнбагыш маен ваклап сәүдә итү оешмаларына 1 литрга 95 сумнан артмаган бәядән (өстәлгән кыйммәткә салымны кертеп) FCA (йөк алучының транспорт чарасына төяп, йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында һәм (яки) ак шикәрне ваклап сәүдә итү оешмаларына 1 килограммга 36 сумнан артмаган бәядән (өстәлгән кыйммәткә салымны кертеп) FCA (йөк алучының транспорт чарасына төяп, йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) үлчәп төрү һәм алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында сатуның планлаштырыла торган күләме турында белешмә кәгазе;»;

9 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «аларның килү» сүзләре алдына «, килгән көнен һәм вакытын күрсәтеп,» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү йә заявканы кабул итүдән баш тарту турында) реестр төзи һәм раслый;»;

13 пунктта:

дүртенче абзацта «үз җитештерүендәге» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартларында» сүзеннән соң «, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «үз җитештерүендәге» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартларында» сүзеннән соң «, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) үлчәп төрү һәм алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында» сүзләрен өстәргә;

14 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап чоры өчен көнбагыш маен ваклап сәүдә итү оешмаларына 1 литрга 95 сумнан артмаган бәядән (өстәлгән кыйммәткә салымны кертеп) FCA (йөк алучының транспорт чарасына төяп, йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында һәм (яки) ак шикәрне ваклап сәүдә итү оешмаларына 1 килограммга 36 сумнан артмаган бәядән (өстәлгән кыйммәткә салымны кертеп) FCA (йөк алучының транспорт чарасына төяп, йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) үлчәп төрү һәм алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында сату фактын раслый торган беренчел документлар реестры (тәэмин итү шартнамәләре, тәэмин итү шартнамәләренә спецификацияләр, товар йөкнамәләре һәм (яки) универсаль тапшыру документлары);»;

15 пунктта:

дүртенче абзацта «үз җитештерүендәге» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартларында» сүзеннән соң «, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «үз җитештерүендәге» сүзләрен төшереп калдырырга, «шартларында» сүзеннән соң «, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) үлчәп төрү һәм алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында» сүзләрен өстәргә;

20 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып 2021 елның 1 апреленнән 30 сентябренә кадәр көнбагыш маеның ваклап сәүдә итү оешмаларына 1 литрга 95 сумнан артмаган бәядән (өстәлгән кыйммәткә салымны кертеп) FCA (йөк алучының транспорт чарасына төяп, йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында һәм (яки) ак шикәрнең ваклап сәүдә итү оешмаларына 1 килограммга 36 сумнан артмаган бәядән (өстәлгән кыйммәткә салымны кертеп) FCA (йөк алучының транспорт чарасына төяп, йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) EXW (йөк җибәрүче складында тапшыру) шартларында, һәм (яки) үлчәп төрү һәм алып килеп бирү өчен өстәмә чыгымнарны тотып калып башка тәэмин итү шартларында сатылган күләме тора.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин